**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025 елның 30 ноябре № 3

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сугышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 30 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан. Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2026 елда 2000 (Ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Юлтимер авылының Совет ур., Игтисамовлар ур. буенча урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Юлтимер авылының Совет урамындагы, Игтисамовлар урамындагы юлларны кардан чистарту; юллардагы чокырларны ремонтлау һәм Юлтимер авылының Совет урамындагы, Игтисамовлар урамындагы юлларны асфальтлау (хезмәт күрсәтүләргә һәм материалга түләү));

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Юлтимер авылының янгын гидрантлары өчен КПА янгын колонкасын сатып алу)" соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 202 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 104 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 104 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Сугышлы авыл җирлегенең Юлтимер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Украинадагы махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 2025 елда 2000 (Ике мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Юлтимер авылының Совет ур., Игтисамовлар ур. буенча урамнарны яктыртуга техник хезмәт күрсәтү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Юлтимер авылының Совет урамындагы, Игтисамовлар урамындагы юлларны кардан чистарту; юллардагы чокырларны ремонтлау һәм Юлтимер авылының Совет урамындагы, Игтисамовлар урамындагы юлларны асфальтлау (хезмәт күрсәтүләргә һәм материалга түләү));

3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Юлтимер авылының янгын гидрантлары өчен КПА янгын колонкасын сатып алу)" соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сугышлы ав., Үзәк ур., 27 йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Сугышлы авыл җирлеге башлыгы А.П.Зыятдинова